| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬ-<br>СКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙ-<br>ОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БУТЛЕРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.06.2019 № 107

Юеш Көрнәле авылы

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 24 апрелендәге 69а номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, 2019 елның 31 маендагы халык тыңлауларының нәтиҗәләрен (тәкъдимнәрен) исәпкә алып

**Бутлеровка авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. 2013 елның 24 апрелендәге 69а номерлы Бутлеровка авыл җирлеге Совет карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә: җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында үзгәртергә:

Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Бутлеровка авыл җирлеге адресы буенча урнашкан территорияләрне.

Җирләрнең категориясе: «Родина» колхозы милкендә булган крестьян (фермер) хуҗалыгын алып бару өчен рөхсәт ителгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр. Гомуми мәйданы 28,8 га тәшкил иткән АХ1 зонасына (авыл хуҗалыгы җирләре зонасы) ия булган участокны СХ2 зонасына (авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм корылмаларын урнаштыру

зонасы) үзгәртергә. Әлеге территориаль зонаны үз эченә алган җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16: 05: 050701: 129. (Кушымта).

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Бутлеровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Ф.А. Хайрутдинова**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ БУТЛЕРОВСКОЕ
1605-11124/13
СОВЕТ БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ